**Белем мониторингы**

**Татар теле (21 нче код)**

**VI сыйныф**

**Татар телендә гомуми белем бирү мәктәпләренең VI сыйныф укучыларының татар теленнән белем һәм күнекмәләрен тикшерү өчен биремнәр**

**Максат: VI** сыйныф укучыларының татар теленнән белем һәм күнекмәләре сыйфатын ачыклау

**Контроль формасы:** БРИ (бердәм республика имтиханы) форматына туры килә торган тестлар.

**Эшнең эчтәлеге:** ике өлештән тора.

Җавапларны сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр (1 нче өлеш) 16 биремне үз эченә ала. Һәр биремгә 4 вариантта җавап тәкъдим ителә. Укучы үзе дөрес дип тапкан бер җавапны сайлап алырга тиеш.

Кыска җаваплар бирүне таләп иткән биремнәр (2 нче өлеш) җөмлә һәм җөмләгә нигезләнгән 4әр биремнән тора. Мондый биремнәрнең җавабы кыскача формалаштырыла һәм сүз яисә хәрефләр белән языла.

**Бәяләү:** 1 нче өлешнең һәр дөрес җавабын – 1әр балл, ә 2 нче өлешнең һәр дөрес җавабын 2шәр балл белән бәяләргә тәкъдим ителә.

| Бирем | Бүлек | Биремнәрнең эчтәлеге | |
|---|---|---|---|
| 1 | Фонетика | Аваз һәм хәреф | |
| 2 | Фонетика | Сузык авазлар | |
| 3 | Орфография | Ь һәм ъ билгеләренең язылышы. Һ, ң хәреве | |
| 4 | Лексикология | Сүзнең мәгънәсе.<br>Сүзнең лексик мәгънәсе.<br>Антонимнар. Омонимнар. | |
| 5 | Лексикология | Кулланылыш ягыннан сүзлек составы. Фразеологик әйтелмәләр. | |
| 6 | Морфемика һәм сүз ясалышы | Сүзләрнең ясалыш буенча төрләре. | |
| 7 | Морфемика һәм сүз ясалышы | Сүзләрнең ясалыш буенча төрләре. | |
| 8 | Морфемика һәм сүз ясалышы | Сүзләрнең ясалу ысуллары. Сүзләрнең ясалыш буенча төрләре. | |
| 9 | Морфемика һәм сүз ясалышы | Сүзләрнең ясалу ысуллары. Кушымчалар һәм аларның төрләре . | |
| 10 | Морфемика һәм сүз ясалышы | Сүзләрнең ясалышы һәм төзелеше. Кушымчалар һәм аларның төрләре. | |
| 11 | Морфемика һәм сүз ясалышы | Сүзләрнең ясалышы һәм төзелеше.<br>Кушымчалар һәм аларның төрләре | |
| 12 | Морфология | Сүз төркемнәрен тикшерү. | |
| 13 | Морфология | Сүз төркемнәрен тикшерү. | |
| 14 | Морфология | Сүз төркемнәрен тикшерү. | |
| 15 | Синтаксис | Әйтү максаты буенча җөмлә төрләрен аеру. Җөмлә кисәкләрен билгеләү. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. | |
| 16 | Синтаксис | Җөмлә төрләре. Җөмлә кисәкләрен билгеләү. | |
| 17 | Синтаксис | Җөмлә кисәкләрен билгеләү. | |
| 18 | Морфология | Сүз төркемнәрен тикшерү. | |
| 19 | Морфология | Сүз төркемнәрен тикшерү. | |
| 20 | Орфография | Сүзләрнең әйтелеш язылышы белән туры килмәгән очракларны билгеләү. Авазларны билгеләү. | |

**Татар теле (21 нче код)**

**VI сыйныф**

I **вариант**
**1 нче өлеш**

**1.** Кайсы төркемдә **аваз һәм хәреф саны** туры килә?
1) өчен, ат, янәшә
2) гадәт, Агыйдел, сәнгать
3) ямь, дәвер, әһәмият
4) ватык, кагыйдә, гомер

**2. Васыять** сүзендә нинди сузык авазлар бар?
1) а, и, ә
2) а, ы я
3) а, ы, е
4) а, ы, э

**3.** Кайсы төркемдәге сүзләрдә күпнокталар урынына **Ң хәрефе** языла?
1) мә...ге, ти...ләү, иртә...ге
2) боры...гы, ди...гез, тә...кә
3) бәрә...ге, ши...гән, я...гырау
4) ә...кәй, у...ган, я...гыр

**4.** Түбәндәге мисалларда сүзләр үзара **антоним** булган вариантларны күрсәтегез.
1) тагын, яңадан, арт, ал
2) күңел, җан, әҗәт, хаҗәт
3) ару, талчыгу, матур, ямьсез
4) дус, дошман, биек, тәбәнәк

**5.** Кайсы пунктта **фразеологик берәмлекләр рәте** бирелгән?
1) колак торгызу, акылга утыру
2) белем иясе, кычкырып җибәрү
3) тау куышы, миләш яфрагы
4) ватык көзге, авыз турсайту

**6. Миләш чыпчыгы, үги ана яфрагы, тавыш бирү** сүзләре сүз ясалышының кайсы ысулы буенча ясалганнар?
1) сүзләрне кыскарту юлы белән
2) сүзгә кушымчалар өстәү юлы белән
3) сүзләрне тезү ысулы белән
4) болар сүзтезмәләр

**7. Ясалма сүзләр** кайсы төркемдә?
1) сәхнә, күңел
2) язмыш, үлем
3) тана, ихтимал
4) гыйбрәт, тамаша

**8. Сыйфат ясагыч кушымчалар** кайсы төркемдә бирелгән?
1) -тын/-тен, -лап/-ләп
2) -ымта/-емтә, -гар/-гәр
3) -ләтә/-лата, -лаш/-ләш
4) -сыл/-сел, -ык/-ек

**9. Бәйләгеч кушымчалар** кайсы рәттә күрсәтегез?
1) -ның, -нең, -га, -гә, -дан, -дән
2) -лык, -лек, -ла, -лә, -чы, -че
3) -дай, -дәй, -ча, -чә, -лап, -ләп
4) -ган, -гән, -ты, -те, -ачак, -әчәк

**10.** Кайсы сүз **тамыр, сүз ясагыч һәм бәйләгеч кушымчалар**дан тора?
1) яшьлек
2) утынлыкта
3) киләчәк
4) баручы

**11. Сыйфат ясалу тибы**на керә торган ысуллар кайсы төркемдә бирелгән?
1) уйланма, зурлама
2) кайгырма, тавышланма
3) юллама, кабартма
4) ясалма, чагыштырма

**12.** Җөмләдә аерып бирелгән исемнең килешен билгеләгез. *Гариф карышмады, тагын* ***баракка*** *китте.*
1) чыгыш килеше
2) юнәлеш килеше
3) төшем килеше
4) урын-вакыт килеше

**13. Минем** алмашлыгының төркемчәсе -
1) күрсәтү алмашлыгы
2) зат алмашлыгы
3) тартым алмашлыгы
4) билгеләү алмашлыгы

**14. Билгесез үткән заман хикәя фигыль кушымчалары**н күрсәтегез.
1) –ды, -де, -ты, -те
2) –ган, -гән, -кан, -кән
3) –ганчы, -гәнче, -канчы, -кәнче
4) –кач, -кәч, -гач, гәч.

**15.** Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрен билгеләгез. – *Җыеп ал!*
1) хикәя
2) сорау

3)	боеру
4)	тойгылы

**16.** *Дуслары* ***ялварса да****, ул кайтмады.*  җөмләсендә аерып бирелгән сүз:
1)	аергыч
2)	хәл
3)	тәмамлык
4)	хәбәр

**2 нче өлеш**

Әлеге өлештәге биремнәргә җавапны җавап бланкына бирем санынннан уң якка беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифрны аерым шакмакка языгыз. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда буш шакмаклар калдырырга кирәкми.

*Гомер узган саен күрәм: начар мин,*
*Языгым белеп* ***язмыштан*** *качалмыйм.*

**17.** Аерып бирелгән сүз җөмләнең нинди кисәге булып тора?
**18.** **Белеп** фигыленең төркемчәсен языгыз.
**19.** Бирелгән җөмләдән  алмашлыкны күчереп языгыз.
**20.** **Языгым** сүзендә ничә аваз бар?

## Татар теле (21 нче код)

## VI сыйныф

## II вариант

**1 нче өлеш**

**1.**  Кайсы төркемдә **аваз һәм хәреф саны** туры килә?
1)   кара, өстәл, эчендә
2)   авыл, яисә, дәвам
3)   әкият, гаять, ямь
4)   табигать, каләм, кавын

**2.**  **Югыйсә**  сүзендә нинди сузык авазлар бар?
1)   [ю], [и], [е]
2)   [ю], [и], [ә]
3)   [у], [и],  [ә]
4)   [у], [ы], [ә]

**3.** **Ъ хәрефе**  нинди билге буларак кулланыла?
1)   калынлык
2)   аеру
3)   аеру һәм калынлык
4)   нечкәлек

**4.**  **Омоним** терминына кайсы аңлатма туры килә?
1)   әйтелеше төрле, әмма мәгънәсе бертөрле
2)   капма-каршы мәгънәле сүзләр
3)   язылышы бер үк, ләкин әйтелеше төрле
4)   язылышы һәм әйтелеше бер, ләкин мәгънәсе төрле

**5.** Кайсы рәттә **фразеологик берәмлекләр** бирелгән?
1)   бака үләне, тимер юл, сыйныф журналы
2)   аптырап калу, көмеш алка, егыла язу
3)   сүзсез калу, ачык чырай, күз буяу
4)   кыш җитү, куып килү, аптырап калу

**6.** **Ясалма сүз** кайсы рәттә?
1)   ызан
2)   тузан
3)   тәпән
4)   чапан

**7.** Кайсы төркемдә **сүзъясагыч кушымчалар** ялганып ясалган сүзләр бирелгән?
1)   берни, яланөс
2)   өчпочмак, тимераяк
3)   тигезләмә, катыргы
4)   зифа буйлы, кычкырып җырлау

**8.** *Баскыч, бүлмә, юлчы* сүзләре **сүз ясалышының кайсы ысулы** буенча ясалганнар?
1)   сүзъясагыч кушымчалар кушылу белән
2)   сүзләрне кыскарту юлы белән
3)   сүзгә яңа мәгънә өстәү юлы белән
4)   сүзләрне кушу юлы белән

**9.** **Сыйфат ясагыч кушымчалар** кайсы рәттә бирелгән?
1)  -лап/-ләп, -ча/-чә
2)  -сыл/-сел, -ык/-ек,
3)  -ымта/-емтә, -лык/-лек
4)  -ла/ -лә, -лаштыр/-ләштер

**10.**  **Бәйләгеч кушымчалар** кайсы рәттә бирелгән?
1)   -у, -ү, -ырга, -ергә, -лык, -лек
2)   -ган, -гән, -кач, -кәч, -чы, -че
3)   -да, -дә, -ым, -ем, -ның, -нең

4) -ды, -де, -ыр, -ер, -даш, -дәш

**11.** Кайсы сүз **тамыр, сүз ясагыч һәм бәйләгеч кушымчалардан** тора?
1) башлык
2) аулап
3) балыкчыда
4) авылның

**12. Төшем юнәлешендәге фигыльләр**не күрсәтегез.
1) бирелә, ашала, куела
2) киенәм, бизәнәм, юынам
3) эшләшә, барыша, сибешә
4) менгезгән, җиткер, уйнат

**13.** Кайсы төркемдә **билгеләү алмашлыклары** бирелгән?
1) берничә, кемдер, ниндидер
2) һәммә, бөтен, барысы
3) һичкая, бернинди, һичкайда
4) ничә, кем, нигә.

**14.** Җөмләдә аерып бирелгән исемнең килешен билгеләгез. *Төрле* ***йортлардан*** *арбаларына тырмаларын, сукаларын, орлык ашлыкларын төяп, безнең шикелле сабанчылар чыгып килә.*
1) юнәлеш килеше
2) төшем килеше
3) чыгыш килеше
4) урын-вакыт килеше

**15.** Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрен билгеләгез.
*Егетләр! Бәшир абзый үзе чыккан, зурлаган!*
1) хикәя
2) сорау
3) боеру
4) тойгылы

**16. Бүген** клубка күңел ачарга, биергә барабыз. җөмләсендә аерып бирелгән сүз җөмләдә -
1) тәмамлык
2) хәл
3) аергыч
4) хәбәр

## 2 нче өлеш

Әлеге өлештәге биремнәргә җавапны җавап бланкына бирем санынnan уң якка беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифрны аерым шакмакка языгыз. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда буш шакмаклар калдырырга кирәкми.

*Табигать баласы булып, дөньяның бар матурлыгын кечкенәдән күреп, тоеп үскәннән киләдер. Аның күңеленә табигатьнең мең төрле күренеше, сурәте, тавышы, хәтта* ***кыргый*** *исләренә хәтле үтеп керә, саклана. Ул дөньяны күзләре белән генә түгел, күңеле белән күрергә дә өйрәнә.*

**17.** Аерып бирелгән сүз җөмләнең нинди кисәге булып тора?
**18.** Җөмләләрдән зат алмашлыкларын табып, күчереп языгыз.
**19. Дөньяның** сүзенең килешен билгеләгез.
**20. Табигать** сүзендә ничә аваз бар?

## Татар теле (21 нче код)

## VI сыйныф

## Җаваплар

| | I вариант | II вариант |
|---|---|---|
| 1 | 3 | 1 |
| 2 | 1 | 3 |
| 3 | 3 | 3 |
| 4 | 4 | 4 |
| 5 | 1 | 3 |
| 6 | 3 | 2 |
| 7 | 2 | 3 |
| 8 | 4 | 1 |
| 9 | 1 | 2 |
| 10 | 2 | 3 |
| 11 | 4 | 3 |
| 12 | 2 | 1 |
| 13 | 2 | 2 |
| 14 | 2 | 3 |
| 15 | 3 | 4 |
| 16 | 4 | 2 |
| 17 | тәмамлык | аергыч |
| 18 | хәл фигыль | аның,ул |
| 19 | мин | иялек килеше |
| 20 | 7 аваз | 7 |